ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 октябрь 2020ел № 5230

Башкарма комитетның 2013 елның 7 августындагы 4713 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 7 августындагы 4713 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3274 номерлы, 2018 елның 28 апрелендәге 2396 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 6594 номерлы, 2020 елның 13 августындагы 3935 номерлы карарлары редакциясендә) расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге пунктчаны өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 13 июлендәге 587 номерлы карары белән (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 587 номерлы карары) (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 24.07.2020, № 55, ст. 1399);»;

2) 1.5 пунктта:

- икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза бирүче (бюджет өлкәсе хезмәткәрләре һәм торак төзелешен үстерүне финанслауда катнашучы предприятиеләр хезмәткәрләре өчен) - даими яшәү урыны буенча теркәлгән, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә дәүләт ярдәме алу өчен исәпкә кую максаты белән, торак шартларын яхшыртуга аның әгъзасы булып торган мохтаҗ гаилә исеменнән (яисә үз исеменнән, әгәр никахта тормаса) гариза биргән Татарстан Республикасында яшәүче;

- түбәндәге эчтәлектәге пунктчаларны өстәргә:

«гариза бирүче (яшь гаиләләр өчен) - «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә социаль ипотека системасында

торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә кую максаты белән, аның әгъзасы булып торган яшь гаилә исеменнән гариза биргән Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданы;

яшь гаилә - никахлашкан, ире яки хатынының яше 35 яшьтән артмаган, шул исәптән иждивениесендә бала (балалар) булган гаилә яки яше 35 яшьтән артмаган бер ата-анадан торган, иждивениесендә бала (балалар) булган тулы булмаган гаилә (алга таба - яшь гаилә)»;

3) 2.5 пунктта:

- икенче багананың 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Гариза (1 нче кушымта - бюджет өлкәсе хезмәткәрләре һәм предприятиеләр хезмәткәрләре өчен; 8 нче кушымта – яшь гаиләләр өчен);»;

- өченче баганага түбәндәге сүзләрне өстәргә: «ТР Министрлар Кабинетының 587 номерлы карарының 1 пункты»;

4) 2.6 пунктның икенче баганасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- аерым затның ул ия булучы (ия булган) күчемсез милек объектларына хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;»;

5) 2.9 пунктта 5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) «яшь гаилә» төшенчәсенә туры килмәү»;

6) 3.4.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә тиешле мәгълүматларны бирү турында запрослар җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрослар.»;

7) кушымтада каралганча 8 нче кушымтаны өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 12 октябрендәге
5230 номерлы карарына
кушымта

Социаль ипотека системасында
торак шартларын яхшыртуга
мохтаҗларны исәпкә кую буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
8 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты Җитәкчесенә

граждан ______________________________
______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
______________________________
______________________________
түбәндәге адрес буенча яши:
______________________________
______________________________
(почта индексы, тулы адрес, контакт телефоны)
______________________________
______________________________
______________________________
түбәндәге адрес буенча теркәлгән:
______________________________
(почта индексы, тулы адрес)
______________________________
______________________________
______________________________
______________________________
(теркәлү көне, ае, елы)

Гариза

Сездән______________________________________________________________
(яшәү шартларын яхшыртуга мохтаҗ булу сәбәпләрен күрсәтергә)
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
__________________________________________________________________сәбәпле
_____ кеше составында минем гаиләне яшь гаилә буларак социаль ипотека системасында торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алуны сорыйм.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары җирле үзидарә органнары тарафыннан гаризада һәм анкетада күрсәтелгән мәгълүматларны тикшерүгә, шулай ук алар һәм махсуслашкан оешма (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды)

тарафыннан исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документларга запрос ясауга ризалык бирәбез.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, безне исәпкә алган очракта, гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә, бер ай эчендә алар турында җирле үзидарә органнарына исәп урыны буенча язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш булуыбыз турында кисәтелдек.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, гаризада күрсәтелгән мәгълүматларга туры килми торган мәгълүматлар ачыклаган очракта, законда билгеләнгән тәртиптә исәптән төшереләчәгебез белән килешәбез.

Моның белән тиешле салым органнарында һәм күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән килешүләр төзүне дәүләт теркәвенә алу органнарында минем керемнәрем һәм милек хокукында мин ия булган милек турында мәгълүматларны тикшерергә ризалык бирәм.

Гариза бирүче ________________________________________________ __________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча) (имза)

Хокукка сәләтле гаилә әгъзалары:

1.____________________________________________________________

2.____________________________________________________________

3.____________________________________________________________

4.____________________________________________________________

(гаиләнең хокукка сәләтле барлык әгъзаларының имзалары)

«____» ____________ 20___ ел

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева